ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30 04 2021 г. № 126

Түбән Кама шәһәре автомобиль юллары буенча транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Региональ яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буенча транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү яисә туктату тәртибен раслау турында» карары, Түбән Кама шәһәре Уставы нигезендә, Түбән Кама шәһәре автомобиль юлларының максималь йөкләнеше сәгатьләрендә үткәрү сәләтен арттыру максатларында, карар бирәм:

1. 2021 елның 30 маеннан 2021 елның 1 сентябренә кадәр, күрсәтелгән урамнар буенча 06.00 дән 20.00 сәгатькә кадәр 15 тоннадан артык рөхсәт ителгән масса белән транспорт хәрәкәтен тыеп, Сүбәләк автомобиль юлы, Пролетар ур., Индустриаль ур., Мурадьян ур., Корабельная ур., Субай урамнары буенча шәһәр территориясенә 15 тоннадан артык рөхсәт ителгән масса белән йөк транспорт чаралары керүгә чикләү кертергә.

2. 2021 елның 30 маеннан 2021 елның 1 сентябренә кадәр Түбән Кама шәһәренең Вахитов проспекты, Сүбәләк автоюлы, Менделеев урамы, Сөембикә урамы, Корабельная урамы белән киселешеннән Төзүчеләр проспекты белән киселешенә кадәр Студентлар урамы, Химиклар проспекты, Яшьлек урамы, Тукай урамы, Баладурин урамы, Бызов урамы, Октябрьнең 50 еллыгы урамы, Җиңүнең 30 еллыгы урамы белән киселешеннән Мурадьян урамына кадәр Тынычлык проспекты, Химиклар проспекты белән киселешеннән Тынычлык проспекты белән киселешенә кадәр Җиңүнең 30 еллыгы урамы, Шинчылар проспекты, Төзүчеләр проспекты, Бызов урамы белән киселешеннән Мурадьян урамы белән киселешенә кадәр Урман урамы, Мурадьян урамы буенча автомобиль юллары буйлап 06.00 дән 20.00 сәгатькә кадәр 5 тоннадан артык рөхсәт ителгән масса белән йөк транспорт чараларының хәрәкәтен тыюны кертергә.

3. Әлеге карар белән билгеләнгән хәрәкәтне вакытлыча чикләүләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы карары белән расланган региональ яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буенча транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү яисә туктатуны гамәлгә ашыру Тәртибенең IV бүлегендә каралган очракларга кагылмый.

4. «Буран» операциясен үткәрү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының тиешле норматив-хокукый акты кабул ителгән очракта, операция булган вакытта күрсәтелгән хокукый акт нигезендә Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә транспорт чаралары хәрәкәтен чикләргә.

5. «Түбән Кама шәһәренең бердәм заказчы дирекциясе» МБУ:

5.1. «Юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары. Юл билгеләрен, тамгаларын, светофорларны, юл киртәләрен һәм юнәлтү җайланмаларын куллану ка-гыйдәләре» Р 52289-2019 ГОСТ таләпләре һәм Россия Федерациясенең Юл хәрәкәте кагыйдәләре нигезендә, әлеге карарның 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән урамнарда транспорт чаралары хәрәкәтен чикләүче тиешле юл билгеләрен урнаштыруны тәэмин итәргә;

5.2. транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү кертелгән автомобиль юллары участокларын урап узу мөмкинлеге турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә;

5.3. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама районы буенча идарәсенең Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы дәүләт инспекциясе бүлеге белән берлектә автомобиль юлларын максималь йөкләү сәгатьләрендә транспорт чараларының хәрәкәт интенсивлыгы мониторингын үткәрүне тәэмин итәргә.

6. Тәкъдим итәргә:

6.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама районы буенча идарәсенең Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы дәүләт инспекциясе бүлегенә әлеге карарның 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән Түбән Кама шәһәре автомобиль юллары участокларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү чорында юл хәрәкәте иминлеген үтәүне контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

6.2. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән урамнар буенча шәһәр территориясенә 15 тоннадан артык рөхсәт ителгән масса белән транспорт чаралары керүгә вакытлыча чикләү кертү һәм әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән Түбән Кама шәһәренең автомобиль юллары буйлап 5 тоннадан артык рөхсәт ителгән масса белән транспорт чараларын хәрәкәтенә тыю кертү турында мәгълүматны рәсми сайтта бастырырга;

6.3. Түбән Кама муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә массакүләм мәгълүмат чаралары аша әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән урамнар буенча шәһәр территориясенә 15 тоннадан артык рөхсәт ителгән масса белән транспорт чаралары керүгә вакытлыча чикләү кертү һәм әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән Түбән Кама шәһәренең автомобиль юллары буйлап 5 тоннадан артык рөхсәт ителгән масса белән транспорт чараларын хәрәкәтенә тыю кертү турында хәбәр итәргә.

7. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларының матбугат басмаларында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы,
Җитәкче урынбасары А.Р. Гарифуллин